**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Югары Ырга авыл җирлеге составына керүче Югары Ырга авылында узган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**КАРАР**

2019 елның 7 нче ноябре № 1

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының ”Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Законының 35 маддәсе нигезендә “Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Югары Ырга авыл җирлеге составына керүче Югары Ырга авыл торак пунктларында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре) 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- энергия саклаучы урам яктырткычларын сатып алу һәм урнаштыру;
- авыл җирлеге торак пунктларында юл кырыйларында чүп үләннәрен чабу
- Яңа Ырга авылындагы Мәктәп һәм Ворошилов урамнарындагы юлларны ремонтлау;
-Югары Ырга авылы М. Җәлил урамы буенча вак таш катламы җәю;
- авыл җирлеге торак пунктларында юлларны кышкы карап тоту;;
- су белән тәэмин итү

соравы (мәсьәләсе) буенча 2019 елның 7 нче ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенының сайлау хокукына ия катнашучылары исемлегенә 145 кеше кертелде, тавыш бирүдә җыенның 123 кешесе катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

“Әйе” позициясе өчен 123 җыенда катнашучы тавыш биргән;

“Юк” позициясе өчен 0 җыенда катнашучы тавыш биргән.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Югары Ырга авыл җирлеге составына керүче Югары Ырга авыл торак пунктында гражданнар җыеннарын булды дип, гражданнар җыеннары нәтиҗәләрен **дөрес** дип танырга.

2. “Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Югары Ырга авыл җирлеге составына керүче Югары Ырга авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре) 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- энергия саклаучы урам яктырткычларын сатып алу һәм урнаштыру;
- авыл җирлеге торак пунктларында юл кырыйларында чүп үләннәрен чабу

- Яңа Ырга авылындагы Мәктәп һәм Ворошилов урамнарындагы юлларны ремонтлау;

-Югары Ырга авылы М. Җәлил урамы буенча вак таш катламы җәю;

- авыл җирлеге торак пунктларында юлларны кышкы карап тоту;

- су белән тәэмин итү

соравы (мәсьәләсе) буенча карарны **кабул ителде** дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Югары Ырга авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Югары Ырга авылы, М.Җәлил урамы, 18 йорт; Яңа Ырга авылы, Мәктәп урамы, 48 йорт; һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"ында урнаштырырга.

4. Карарны Татарстан Республикасы үзидарәлек хокукый норматив актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Югары Ырга авыл җирлеге башлыгы Р.Н.Багаутдинов